РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ
«ГОРОД ЧИСТОПОЛЬ»
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ

**ЧИСТАЙ
ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ**

***Решение*** ***Карар***

**04 апрель 2024 ел** **Чистай шәһәре** **№29/2**

Татарстан Республикасы Чистай шәһәр
Чистай муниципаль районы Советының
2017 елның 9 февраленнән 12/6 номерлы
"Чистай" индустриаль парк территориясендә
сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген гамәлгә
ашыручы оешмаларга
арендага бирелгән җирләр өчен
аренда хакыннан азат итү турында»гы
карарга үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының "Чистай шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясендә инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру, өстәмә эш урыннары булдыру максатларында, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Советы

КАРАР ИТӘ:

1. «Чистай «индустриаль паркы территориясендә сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны арендага бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда хакыннан азат итү турында» Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының 09.02.2017 12/6 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

-1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.«Чистай» индустриаль паркы территориясендә сәнәгать-җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Чистай шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге арендага бирелгән җир кишәрлекләре өчен аренда хакыннан 8 елга азат итәргә.»

2. Әлеге карарны "Чистай хәбәрләре" газетасында һәм "Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында" бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (chistopol.tatarstan.ru)..

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Чистай шәһәр Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутатлык эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
Чистай шәһәре башлыгы в.б. Ксенофонтов М.И.